**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3464**
**05.07.2019**

Муниципаль ихтыяҗлар өчен күчемсез
милек объектын кире алу турында

Җирле әһәмияткә ия объектлар төзү максатында, РФ Җир кодексының 11, 39.22, 49, 56.2, 56.3, 56.6 - 56.8 маддәләре, Башкарма комитетның «ГЭС поселогының 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9, 10 торак комплексларын һәм ЗЯБ поселогын межалау проектларын раслау турында» 2007 елның 2 ноябрендәге 4211 нче карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Муниципаль ихтыяҗлар өчен Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, ЗЯБ поселогы, 14/10 йорт адресы буенча урнашкан Кириллов Артем Сергеевич милкендәге, төзелеш мәйданы 1274 кв.м (кадастр номеры 16:52:000000:3212) булган төзелеше тәмамланмаган объектны – 14/10 балалар бакчасы бинасын кире алырга.

2. Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенә:

1) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 10 көн эчендә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә;

2) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 10 көн эчендә, законда билгеләнгән тәртиптә, әлеге карарның күчермәсен әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән кире алына торган күчемсез милек объектына хокукы булган затка җибәрергә;

3) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 10 көн эчендә әлеге карарның күчермәсен Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенең Яр Чаллы бүлегенә җибәрергә;

4) кире алу нәтиҗәсендә туктатылган хокукларны һәм китерелгән зыянның күләмен бәяләү, шулай ук кире алына торган күчемсез милек объектына алмашка бирелә торган күчемсез милекне бәяләү өчен бәяләүче оешманы билгеләргә;

5) күчемсез милек объектын кире алу буенча эш йомгаклары нигезендә кире алу турында килешенү әзерләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин